СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

28.10.2022　　　　с. Русское Макулово　　　　26-144

Югары Ослан муниципаль районының  Макыл авыл җирлеге Рус Макылы авылы территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Макыл авыл җирлеге Уставы ст. нигезендә, Рус Макылы авылы торак пунктының бер өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 19 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Макыл авылы җирлеге Рус Макылы авылы территориясендә гражданнар арасында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Макыл авылы җирлеге Рус Макылы авылы  территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез килешәсезме:

- Рус Макыл авылында Яр буе урамындагы җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Рус Макылы авылы, Яр буе урамы, 21 йорт адресы буенча 16.00 сәгатьтә.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы урынбасары П.Е. Карпухин